ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

23 май, 2019 ел № 31/12

Яр Чаллы шәһәре муниципаль
берәмлеге административ комиссиясе
составына үзгәрешләр кертү турында

2005 елның 30 декабрендәге «Муниципаль районнар һәм шәһәр округлары җирле үзидарәләренә административ комиссияләр һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен тапшыру турында» 144-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законына нигезләнеп, Башкарма комитетның Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге административ комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында тәкъдимен караганнан соң,

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2017 елның 24 октябрендәге 20/12 санлы Карары (Шәһәр Советының 2018 елның 08 ноябрендәге 27/15, 2018 елның 11 декабрендәге 28/12 санлы Карарлары редакциясендә) белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге административ комиссиясе (алга таба - комиссия) составына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1) комиссия составыннан чыгарырга:

– Ситдыйков Салават Әнәс улын;

2) комиссия составына кертергә:

– Тарабукин Алексей Сергеевичны – комиссия әгъзасы, Үзәк районы хакимияте Башлыгы урынбасары, торак-коммуналь хуҗалыгы һәм төзекләндерү, территориаль иҗтимагый үзидарәне һәм территория Советын үстерү бүлеге башлыгы.

2. Әлеге Карар үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының регламент, хокук тәртибе һәм халык иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

ПРОТОКОЛЬНАЯ ЧАСТЬ
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ